**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**ЧУЛПАНОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**НУРЛАТСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**423015,РТ, .Нурлатский района с.**
**Чулпаново ул.Центральная , 20**
**тел (884345) 3-82-80,факс.3-82-80**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**ЧУЛПАН АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**
**423015,РТ, .Нурлат районы,**
**Чулпан авылы Уэәк урам,**
**20нче йорт**
**тел (884345) 3-82-80,факс.3-82-80**

ОГРН 1021605357366 , ОКПО 02802985 , ОКАТО 92246890000,
ИНН/ КПП 1632001674/163201001 ОКТМО 92646490

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» октябрь 2019 ел № 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлеге Чулпан авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Чулпан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Чулпан авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авылында М.Җәлил урамы, Мәктәп, Төнъяк, Заречная, Пушкин, Садовая, Овражная урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының беренче этабын уздыруны Чулпан авыл җирлеге, Чулпан авылы, М. Җәлил урамы, 70 нче йорт адресы буенча 2019 елның 10 ноябрендә 09 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлегендә Үзәк урам, Луговая урамы, Озерная урамы, Восточная урамы, Подстанция урамында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының икенче этабын уздыруны Чулпан авыл җирлеге, Чулпан авылы, М. Җәлил урамы, 70 нче йорт адресы буенча 2019 елның 17 ноябрендә 09 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлегендә Шоссейная, Тукай, Лермонтов тыкрыгы, Лермонтов урамы, Үзәк тыкрык, Полевая ур., Хастаханә территориясе, Гоголь урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының өченче этабын уздыруны Чулпан авыл

җирлеге, Чулпан авылы, М. Җәлил урамы, 70 нче йорт адресы буенча 2019 елның 24 ноябрендә 09 сәгать 00 минутка билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлеге Чулпан авылында яшәүчеләрнең исемлеген гражданнар җыенын үткәрү өчен территориаль билге буенча бүләргә.

5. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлегендә халык җыены этапларын уздыру һәм оештыруны Чулпан авыл җирлеге башлыгы һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлеге башкарма комитеты тәэмин итә.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Чулпан авыл җирлеге Чулпан авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан тыш, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

1) Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту һәм грунт-вак таш сибү;

2) Су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр башкару;

3) Муса Җәлил һәм Үзәк урамнарына янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру

« РИЗА» «КАРШЫ».

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (игълан итәргә) http://pravo.tatarstan.ru һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлеге Чулпан авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

11. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Чулпан авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф.Зиятдинов